**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 01 2021 № 22

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Аксубай муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы муниципаль программаны раслау турында» 30.10.2019 ел, 756 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Хокук бозуларны профилактикалау системасын үстерү һәм камилләштерү, Аксубай муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын ныгыту, әлеге эшчәнлеккә җәмәгать формированиеләрен һәм халыкны җәлеп итү, шулай ук «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 13.10.2008 ел, 105-ТРЗ номерлы Законны һәм Россия ЭЭМның Аксубай районы буенча бүлегенең 08.01.2021 ел, 87/72 номерлы хаты гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1.Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Аксубай муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы муниципаль программаны раслау турында» 30.10.2019 ел, 756 номерлы карарына, 2020-2022 елларга Аксубай муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча Комплекслы муниципаль программа чаралары исемлеген түбәндәге эчтәлекле 6 нчы бүлек белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

| 6. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә гражданнарга хокукый агарту һәм хокукый мәгълүмат бирү | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Билгеле бер яшәү урыны булмаган затларны социаль адаптацияләү | Башкарма комитетның юридик бүлеге, Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча), халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча), авыл җирлекләре һәм Аксубай штп башкарма комитеты (килешү буенча) | 2020-2022 | МБ | - | - | - | - | - | - | - | - |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга.

3. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карарының үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. Ю. Зайцев